РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 12 2026 елның 27 феврале

## Түбән Кама муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» һәм Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртүне түбәндәге юллар белән тәкъдим итәргә:

 1.1 Түбән Кама муниципаль районы «Красный Ключ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе составын Алабуга муниципаль районы «Костенеево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җир кишәрлекләрен кертү;

 1.2 Түбән Кама муниципаль районы «Прости авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенә керүче җир кишәрлекләрен Алабуга муниципаль районы «Танай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләренә кертү.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына тиешле муниципаль берәмлекләрнең чикләрен тәкъдим ителә торган үзгәртү буенча фикер белдерүне кушымта нигезендә тәкъдим итәргә.

3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырырга, Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында http://e-nkama.ru, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларының басмасында һәм Прости белән Красный Ключ авыл җирлекләренең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы Р.И. Беляев

Түбән Кама муниципаль
районы
Советының
2026 елның 27 февралендәге
12 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләре
(үзгәрешләрен исәпкә алып)
карта-схемасы




Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары

А.В. Умников